**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Түбән Биш авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**№ 139** **2024 елның «29» июле**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Советының 2016 елның 22 апрелендәге 37 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында” карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакында» 2015 елның 22 декабрендәге 650 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында", Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Советының 2016 елның 22 апрелендәге 37 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 пунктта «,Башкарма комитет җитәкчесе» сүзләрен төшереп калдырырга.;

1.2. 6 пунктта «Зәй муниципаль районы «муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә (алга таба – Комиссия)» сүзләрен «Татарстан

Республикасы Зәй муниципаль районындагы хезмәт (вазыйфаи) тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә (алга таба – Комиссия)» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 8 пунктта «Зәй муниципаль районы «муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында Нигезләмәне раслау хакында 2014 елның 14 ноябрендәге 418 номерлы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында Нигезләмә хакында 2018 елның 6 июлендәге 298 номерлы” сүзләренә алмаштырырга;

1.4. Нигезләмәнең 1 нче кушымтасына "Зәй муниципаль берәмлеге Түбән Биш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәттәге үз-үзен тотышына таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе утырышында» сүзләрен «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи) үз-үзен тотышына һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга таләпләрне үтәү комиссиясе утырышында» сүзләренә алмаштырырга.;

1.5. Нигезләмәнең 2 нче кушымтасына "Зәй муниципаль берәмлеге Төгәй авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе утырышында» сүзләрен «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи) тәртибе һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәү комиссиясе утырышында» сүзләренә алмаштырырга.;

1.6. Нигезләмәнең 3 нче кушымтасына «Зәй муниципаль районы «муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе утырышында» сүзләрен «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи) тәртибе һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәү комиссиясе утырышында» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында" бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

**Түбән Биш авыл җирлеге башлыгы урынбасары** **М.М.Мусин**